КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 17 май г.Казань № 459

Татарстан Республикасы территориясендә «Электрон рецепт» сервисын гамәлгә кертү турында

«Дарулар әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә сәламәтлек саклау өлкәсендә мәгълүмати хезмәттәшлекне җайга салу буенча бердәм дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Электрон документлар рәвешендә медицина документациясен алып бару өлешендә сәламәтлек саклау өлкәсендә документлар әйләнеше системасын оештыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 7 сентябрендәге 947н номерлы боерыгын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә дару препаратларына кәгазьдә рәсмиләштерелгән рецептлар белән беррәттән дару препаратларына электрон документ рәвешендә формалаштырылган рецептларны куллану турында карар кабул итәргә.

2. Бу карарга теркәлгән Дару препаратларына электрон документ рәвешендә формалаштырылган рецептлар буенча дару препаратлары җибәрүне гамәлгә ашыру максатларында мәгълүмат алмашу буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турындагы нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 20 көн эчендә медицина һәм фармацевтика оешмаларын «Электрон рецепт» сервисына тоташтыруны оештыру чаралары планын («юл картасын») эшләргә һәм расларга.

4. Татарстан Республикасы территориясендә медицина, фармацевтика эшчәнлеген гамәлгә ашыручы теләсә нинди милек рәвешләрендәге медицина һәм дарухanә оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә электрон документ рәвешендә рецепт-

ларны рәсмиләштергәндә һәм электрон документ рәвешендә рецептлар буенча дару препаратларын җибәргәндә бу карар белән расланган Дару препаратларына электрон документ рәвешендә формалаштырылган рецептлар буенча дару препаратлары җибәрүне гамәлгә ашыру максатларында мәгълүмат алмашу буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турындагы нигезләмәгә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 17 май, 459 нчы
карары белән расланды

Дару препаратларына электрон документ рәвешендә формалаштырылган рецептлар буенча дару препаратлары җибәрүне гамәлгә ашыру максатларында мәгълүмат алмашу буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турында
нигезләмә

1. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә «Электрон рецепт» сервисы ярдәмендә дару препаратларына электрон документ рәвешендә рецептларны рәсмиләштергәндә мәгълүмати хезмәттәшлек (алга таба – шул ук эзлеклелектә электрон рецепт, мәгълүмати хезмәттәшлек) һәм электрон рецептлар буенча дару препаратларын җибәрү тәртибен билгели.

2. «Электрон рецепт» сервисы (алга таба – Сервис) дигәндә «Татарстан Республикасы электрон сәламәтлек саклавы» дәүләт мәгълүмат системасының (алга таба – ТР ЭСС дәүләт мәгълүмат системасы) электрон рецептларны формалаштыру, эшкәртү, саклау, тикшерү һәм алардан файдалану мөмкинлеге бирү, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә электрон рецептлар язып бирү һәм аларны исәпкә алу өчен кулланыла торган мәгълүмат базаларындагы мәгълүматны формалаштыру һәм эшкәртү буенча үзара бәйләнешле аерым функцияләрне башкаруны тәэмин итә торган электрон ярдәмче система аңлашыла.

3. Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар:

Сервисның функциональ операторы;

Сервисның техник операторы;

Сервисны мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр;

Сервистан файдаланучылар.

4. Сервисның функциональ операторы – Сервис эшен оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыручы «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.

5. Сервисның техник операторы – «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Сервисның функциональ операторы тарафыннан билгеләнә торган, Сервисны булдыру, Сервистан файдалану юлы белән мәгълүмат бирү процессын оештыру буенча хезмәтләр күрсәтү, шулай ук аны гамәлгә кертү, эксплуатацияләү, аның эшләвен тәэмин итү һәм аны модернизацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган юридик зат.

6. Сервисны мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр – Татарстан Республикасы территориясендә медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы медицина оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр (алга таба – медицина оешмалары), Татарстан Республи-

касы территориясендә фармацевтика эшчәнлеген гамәлгә ашыручы даруханә оешмалары (даруханәләр, даруханә пунктлары), индивидуаль эшмәкәрләр (алга таба – даруханә оешмалары).

7. Сервистан файдаланучылар – мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучы медицина оешмаларының вәкаләтле медицина хезмәткәрләре тарафыннан рецепт белән җибәрелә торган дару препаратлары билгеләнгән, электрон рецептны рәсмиләштерүгә ризалык биргән физик затлар, яисә аларның законлы вәкилләре, яисә электрон рецепта күрсәтелгән зат яки аның законлы вәкиле тарафыннан дару препаратларын алуга вәкаләт бирелгән физик затлар (алга таба – Сервистан файдаланучының вәкилләре).

8. Электрон рецептны рәсмиләштергәндә һәм электрон рецептлар буенча дару препаратларын җибәргәндә мәгълүмати хезмәттәшлек Сервистан, шулай ук ТР ЭСС дәүләт мәгълүмат системасыннан һәм мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның мәгълүмат системаларыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

9. Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның мәгълүмат системалары мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килергә тиеш.

10. Шәхси мәгълүматларны эшкәрткәндә Сервисның техник операторы һәм мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр шәхси мәгълүматны һәм табиб серенә кертеп каралган белешмәләрне хокуксыз яки очраклы рәвештә файдалану мөмкинлегеннән, бетерүдән, үзгәртүдән, блоклаудан, күчермәсен алудан, бирүдән, таратудан, шулай ук башка хокуксыз гамәлләрдән саклау өчен кирәкле хокукый, оештыру һәм техник чаралар күрә.

11. Электрон рецептны рәсмиләштерү максатларында медицина оешмалары тарафыннан Сервиска түбәндәге мәгълүмат бирелә:

а) электрон рецепт формалаштырыла торган медицина оешмасы турында белешмәләр;

б) электрон рецептны формалаштыручы медицина хезмәткәре турында белешмәләр;

в) дару препаратына мохтаҗ физик зат турында белешмәләр;

г) билгеләнгән дару препаратлары турында белешмәләр.

12. Мәгълүматны Сервиска тапшыру түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

а) үз эшчәнлеген автоматлаштыру өчен кулланыла торган медицина мәгълүмат системасыннан файдаланып, яисә махсуслаштырылган мәгълүмат системаларыннан файдаланып, яисә Сервисның техник операторы тарафыннан бирелә торган программа тәэминаты ярдәмендә медицина оешмалары;

б) үз эшчәнлеген автоматлаштыру өчен кулланыла торган мәгълүмат системасыннан файдаланып, шулай ук Сервисның техник операторы тарафыннан бирелә торган программа тәэминаты белән интеграцияләүдән файдаланып, даруханә оешмалары.

13. Электрон рецептлар буенча дару препаратларын җибәргәндә даруханә оешмалары тарафыннан Сервиска түбәндәге мәгълүмат бирелә:

а) электрон рецепт буенча дару препараты җибәрелгән даруханә оешмасы турында белешмәләр;

б) җибәрелгән дару препаратлары турында белешмәләр;

в) дару препаратын җибәргән фармацевтика хезмәткәре турында белешмәләр.

14. Электрон рецепт буенча дару препаратларын җибәргәндә даруханә оешмасы тарафыннан бирелә торган белешмәләргә Сервисның функциональ операторы тарафыннан бирелгән куркынычсызлык сертификаты белән яки дару препаратын җибәргән даруханә оешмасы хезмәткәренең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән яки аптека оешмасы җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

15. Ташламалы категориядәге гражданнарга дару ярдәмен вакытында һәм сыйфатлы күрсәтү, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүне тормышка ашырганда дарулар белән тәэмин итүне камилләштерү һәм унификацияләү максатында, техник оператор тарафыннан функциональ операторга түләүсез нигездә электрон рецептлар тапшыру тәэмин ителә.

16. Мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру максатларында, Сервисның техник операторы тарафыннан «Электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру тәэмин ителә.

17. Сервистагы мәгълүматны саклау Сервисның техник операторы тарафыннан мәгълүматның оештыру һәм техник саклау чараларын куллану, шулай ук Сервисны эксплуатацияләүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру юлы белән тәэмин ителә.

18. Сервисның техник операторы формалаштырылган электрон рецептлар һәм алар нигезендә җибәрелгән дару препаратлары турындагы мәгълүматны Сервисның мобиль кушымтасында чагылдыруны тәэмин итә.

19. Сервисның мобиль кушымтасында электрон рецепт турында белешмәләр алу өчен Сервистан файдаланучыларны идентификацияләү һәм аутентификацияләү «Электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә, шулай ук Сервистан файдаланучыларның мобиль телефоннары номерлары аша гамәлгә ашырырла

20. Медицина оешмалары, Сервистан файдаланучылар ризалыгы белән, кәгазьдә һәм (яки) электрон рецепт формасында дару препаратларына рецептларны рәсмиләштерүне гамәлгә ашыра. Электрон рецептка медицина хезмәткәренең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела. Электрон рецептның гамәлдә булу срогы кәгазьдәге рецептларның гамәлдә булу срогына туры килә.

21. Электрон рецептларны кулланып, дару препаратларын билгеләү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыклары белән расланган дару препаратларын билгеләү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

22. Сервистан файдаланучының теләге белән медицина хезмәткәре тарафыннан электрон рецептның дубликаты кәгазьдә, шул исәптән 107-1/у формасыдагы рецепт бланкысында бирелергә мөмкин.

23. Электрон рецепт Сервиста аңа уникаль идентификатор бирү һәм QR-код рәвешендә идентификация коды бирү юлы белән теркәлә. Сервиста теркәлгән барлык электрон рецептлар өчен бердәм нумерация кулланыла.

24. Электрон рецепт Сервис ярдәмендә Сервисның мобиль кушымтасына тапшырыла. Сервистан файдаланучылар тарафыннан Сервисны һәм мобиль кушымтаны файдалану түләүсез нигездә башкарыла.

25. Сервистан файдаланучы QR-кодны Сервисның мобиль кушымтасындагы шәхси кабинеттан алырга мөмкин. Сервистан файдаланучылар QR-кодның чит затлар файдалану мөмкинлегеннән саклануын мөстәкыйль тәэмин итә. Даруханә оешмасында дару препараты алу өчен QR-кодны Сервистан файдаланучы вәкиленә шул ук кәгазь документ рәвешендә рецепт тапшыру тәртибендә һәм очракларында тапшырырга рөхсәт ителә. QR-кодны даруханә оешмасына тапшырганда Сервистан файдаланучы QR-кодын тапшыра торган даруханә оешмасына, шулай ук Сервисның техник операторына үзенең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә һәм тапшыруга ризалыгын белдерә.

26. Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеге процессының үзенчәлекләре (файдаланучыларның Сервиска тоташтыруга һәм мәгълүмат алмашуга каратан техник таләпләрен кертеп), шулай ук Сервистан файдаланучыларга хезмәт күрсәтү тәртибе Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

______________________________